Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының кырык җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 октябрь, 2024 ел № 357

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 27 октябрендәге 109 номерлы карары белән (Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 28 февралендәге 140 номерлы, 2023 елның 7 декабрендәге 292 номерлы, 2024 елның 6 мартындагы 308 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Контроль чаралар» 3 бүлегендә:

а) 26 пунктта «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.

б) 28 пунктта:

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.».

- түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«Күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозуларның билгеләре ачыкланса, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителә, мондый мөмкинлек федераль законда контроль рәвеше, Татарстан Республикасының контроль рәвеше турындагы законында күрсәтелгән очракта.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов